Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылы халык җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ КАРАРЫ

2025 елның 16 октябре № 3

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2025 елның 16 октябрендә 13.00 сәгатьтә, 2025 елның 16 октябрендә 14.00 сәгатьтә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: "Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Чертуш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хезмәт итүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, 85 яшьтән өлкәнрәкләр, 1 төркем инвалидларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү (территорияләрне чабу, чүп үләннәрне һәм үсемлекләрне юк итү өчен акча алу, эш өчен килешү буенча түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән авыл юллары чокырларын ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), кышкы чорда юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)."

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 199 кеше кертелгән, 124 кеше тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен тавыш бирде - гражданнар җыенында катнашкан 124 кеше; "Юк" позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында халык җыены булып узды дип танырга.

2. Сорау буенча карар кабул итәргә: "Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Чертуш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хезмәт итүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, 85 яшьтән өлкәнрәкләр, 1 төркем инвалидларыннан тыш һәм алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү (территорияләрне чабу, чүп үләннәрне һәм үсемлекләрне юк итү өчен акча алу, эш өчен килешү буенча түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән авыл юллары чокырларын ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), кышкы чорда юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)."

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: https://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чертуш авылындагы мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә,Чертуш авылы, Сөембикә урамы, 16 нчы йорт янында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы — Н.М. Илалова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ШАХМАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
р 05-11944/14
СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ